КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2026 ел, 7 март 184

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Психик бозылышлары булган инвалидларга даими ярдәм күрсәтеп яшәү буенча социаль хезмәтләр күрсәтүгә норматив чыгымнарны һәм психик бозылышлары булган инвалидларга даими ярдәм күрсәтеп яшәү буенча социаль хезмәтләр күрсәтүгә җан башыннан финанслау нормативын исәпләп чыгару тәртибе һәм 2023 елга психик бозылышлары булган инвалидларга даими ярдәм күрсәтеп яшәү буенча социаль хезмәтләр күрсәтүгә норматив чыгымнарны һәм психик бозылышлары булган инвалидларга даими ярдәм күрсәтеп яшәү буенча социаль хезмәтләр күрсәтүгә җан башыннан финанслау нормативын раслау турында» 2023 ел, 13 май, 592 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Психик бозылышлары булган инвалидларга даими ярдәм күрсәтеп яшәү буенча социаль хезмәтләр күрсәтүгә норматив чыгымнарны һәм психик бозылышлары булган инвалидларга даими ярдәм күрсәтеп яшәү буенча социаль хезмәтләр күрсәтүгә җан башыннан финанслау нормативын исәпләп чыгару тәртибе һәм 2023 елга психик бозылышлары булган инвалидларга даими ярдәм күрсәтеп яшәү буенча социаль хезмәтләр күрсәтүгә норматив чыгымнарны һәм психик бозылышлары булган инвалидларга даими ярдәм күрсәтеп яшәү буенча социаль хезмәтләр күрсәтүгә җан башыннан финанслау нормативын раслау турында» 2023 ел, 13 май, 592 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемендә «һәм 2023 елга психик бозылышлары булган инвалидларга даими ярдәм күрсәтеп яшәү буенча социаль хезмәтләр күрсәтүгә норматив чыгымнарны һәм

психик бозылышлары булган инвалидларга даими ярдәм күрсәтеп яшәү буенча социаль хезмәтләр күрсәтүгә җан башыннан финанслау нормативын раслау» сүзләрен төшереп калдырырга;

әлеге карар белән расланган 2024 елга психик бозылышлары булган инвалидларга даими ярдәм күрсәтеп яшәү буенча социаль хезмәтләр күрсәтүгә норматив чыгымнарны һәм психик бозылышлары булган инвалидларга даими ярдәм күрсәтеп яшәү буенча социаль хезмәтләр күрсәтүгә җан башыннан финанслау нормативын исәпләү тәртибендә:

1.1 пунктта «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2022 - 2024 елларда «Психик тайпылышлары булган инвалидларга бергә яшәү буенча социаль хезмәтләр күрсәтү» пилот проектын гамәлгә ашыру турында» 2022 ел, 19 декабрь, 1366 нчы карары белән расланган 2022 - 2024 елларда психик тайпылышлары булган инвалидларга бергә яшәү буенча социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибе нигезендә (алга таба - Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 19 декабрь, 1366 нчы карары)» сүзләрен «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Психик тайпылышлары булган инвалидларга бергә яшәү буенча социаль хезмәтләр күрсәтү турында» 2022 ел, 19 декабрь, 1366 нчы карары белән расланган Психик тайпылышлары булган инвалидларга бергә яшәү буенча социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибе (алга таба - Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 19 декабрь, 1366 нчы карары) һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2023 - 2026 елларда «Коммерциягә карамаган оешмалар психик тайпылышлары булган инвалидларга бергә яшәү буенча социаль хезмәтләр күрсәтү» пилот проектын гамәлгә ашыру турында» 2023 ел, 18 июль, 860 нчы карары белән расланган 2023 - 2026 елларда коммерциягә карамаган оешмалар психик тайпылышлары булган инвалидларга бергә яшәү буенча социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибе (алга таба - Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 ел, 18 июль, 860 нчы карары) нигезендә» сүзләренә алмаштырырга;

1.4 пунктка «, һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 ел, 18 июль, 860 нчы карары белән расланган 2023 - 2026 елларда коммерциягә карамаган оешмалар психик тайпылышлары булган инвалидларга бергә яшәү буенча социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибе» сүзләрен өстәргә;

1.6 пунктта «психик тайпылышлары булган гражданнар өчен билгеләнгән интернат йортларда» сүзләрен «социаль хезмәт күрсәтү йортлары һәм коммерцияле булмаган оешмалар» сүзләренә алмаштырырга;

IV бүлектә:

исемендә «психик тайпылышлары булган гражданнар өчен билгеләнгән интернат йортларда» сүзләрен төшереп калдырырга;

4.1 пунктның беренче абзацында «психик тайпылышлары булган гражданнар өчен билгеләнгән интернатйортларда» сүзләрен төшереп калдырырга;

2. Бу карарның гамәле 2026 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин